**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы**

**Карар**

**№ 3** **«16» октябрь 2020 ел**

«Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлегенең
Иске Кармәт авыл җирлегендә
халык җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Аксубай муниципаль районы «Иске Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Кармәт авылы, Ленин урамы, 37 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында 2020 елның 26 октябрендә сәгать 11: 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Иске Кармәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уздырырга.

2. "2021 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Иске Кармәт торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме?:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Кармәт авылы юлларына вак таш сатып алу;
- вак таш түшәмле юл полотносы урнаштыру (грунтлау, гредлау, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- кышкы чорда юлларны карап тоту (Иске Кармәт авылы юлларын кардан чистарту) - килешү буенча эш өчен түләү).

II. Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү:

- чишмәне төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

III. Каты коммуналь калдыклар җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- каты коммуналь калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу.

"ӘЙЕ" "ЮК"

3. Әлеге карарны Иске Кармәт авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ игълан итәргә.

Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы В.Г.Парфенов